ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» сентябрь 2026 ел № 733

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында**

“Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы ТР Законы һәм “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында” Арча район Советының 2021 елның 02 февралендәге 42 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзергә;
2. Расларга:

Арча муниципаль районы административ комиссиясе составын (1 нче кушымта);

Арча муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын (2 нче кушымта);

3. Арча муниципаль районы административ комиссиясенең вәкаләтләр чоры әлеге административ комиссиянең беренче утырышы көненнән башлана һәм 5 ел тәшкил итә.

4. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында” 2021 елның 03 мартындагы 130 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында” 2021 елның 03 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган Арча муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында" 2022 елның 31 маендагы 408 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында” 2021 елның 03 мартындагы 130 номерлы Татарстан

Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган Арча муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” (2022 елның 31 маендагы 408 номерлы үзгәрешләр белән) 2023 елның 15 декабрендәге 1173 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында” 2021 елның 03 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган Арча муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” (2023 елның 15 декабрендәге 1173 номерлы үзгәрешләр белән) 2025 елның 18 мартындагы 249 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында” 2021 елның 03 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган Арча муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” (2022 елның 31 маендагы 408 номерлы, 2023 елның 15 декабрендәге 1173 номерлы, 2025 елның 18 мартындагы 249 номерлы үзгәрешләр белән) 2026 елның 04 мартындагы 186 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында” 2021 елның 03 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган Арча муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” (2022 елның 31 маендагы 408 номерлы, 2023 елның 15 декабрендәге 1173 номерлы, 2025 елның 18 мартындагы 249 номерлы, 2026 елның 04 мартындагы 186 номерлы үзгәрешләр белән) 2026 елның 19 мартындагы 231 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында” 2021 елның 03 мартындагы 130 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты карары белән расланган Арча муниципаль районы административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында” (2022 елның 31 маендагы 408 номерлы, 2023 елның 15 декабрендәге 1173 номерлы, 2025 елның 18 мартындагы 249 номерлы, 2026 елның 04 мартындагы 186 номерлы, 2026 елның 19 мартындагы 231 номерлы үзгәрешләр белән) 2026 елның 13 июлендәге 601 номерлы.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.И.Абдуллин

1 кушымта

**РАСЛАНДЫ**

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
“10” 09 2026 ел № 733
карарына

**Арча муниципаль районы**
**Административ комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Абдуллин Ленар Илсур улы | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Баһаветдинов Рамил Рафис улы | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Әсхәдуллина Энҗе Сәгыйть кызы | - административ комиссиянең баш белгече, комиссия секретаре; |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Сәгыйтова Ләйсән Гәрәфетдин кызы | - Арча район Советы Аппаратының юридик мәсьәләләр бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Хәсәнов Илнур Мәхмүт улы | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе; |
| Фәсхетдинова Энҗе Фирдәүс кызы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының инфраструктура үсеше бүлегенең ТКХ, энергетика һәм элемтә секторы мөдире; |
| Билалова Гөлназ Хөрмәтулла кызы | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Арча шәһәре Башкарма комитетының 1 категорияле белгече (килешү буенча); |
| Сиражиев Илһам Габтелнур улы | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе. |

2 кушымта

**РАСЛАНДЫ**

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
“10” 09 2026 ел
№ 733
карарына

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Административ комиссиясенең**
**ЭШ РЕГЛАМЕНТЫ**

Әлеге Регламент Арча муниципаль районының административ комиссиясенең (алга таба – административ комиссия) эш тәртибен билгели.

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Административ комиссия Арча районы башкарма комитеты тарафыннан төзелгән.

1.2. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы, “Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы законы) һәм Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары белән башкара.

1.3. Административ комиссия административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы чикләрендә эшли.

1.4. Административ комиссиянең бурычлары булып Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә административ хокук бозу турындагы һәр эшне һәрьяклап, тулы, объектив һәм үз вакытында карау, чыгарылган карарның үтәлешен тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү тора.

1.5. Арча муниципаль районы административ комиссиясенең вәкаләтләр чоры әлеге административ комиссиянең беренче утырышы көненнән башлана һәм биш ел тәшкил итә. Күрсәтелгән срок тәмамлангач, административ комиссия үз вәкаләтләрен

яңа составтагы административ комиссиянең беренче утырышы көненә кадәр башкаруын дәвам итә.

1.6. Административ комиссия әгъзасының вәкаләтләре Татарстан Республикасы Законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

1.7. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да соңга калмыйча вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан административ комиссия әгъзасы урынына Арча район Башкарма комитеты административ комиссиянең яңа әгъзасын билгеләргә тиеш.

1.8. Административ комиссиянең административ комиссиянең тулы исеме булган мөһере була.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Административ комиссия административ комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, җаваплы сәркатибеннән һәм Арча район башкарма комитеты билгеләгән административ комиссия әгъзаларыннан (алга таба – административ комиссия әгъзалары) тора.

2.2. Административ комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.3. Административ комиссиянең шәхси һәм сан составы Арча район башкарма комитеты тарафыннан кимендә 5 кеше итеп билгеләнә һәм пар булмаган санны тәшкил итәргә тиеш.

2.4. Административ комиссия составына даими штат нигезендә Административ комиссиянең җаваплы сәркатибе керә. Административ комиссиянең башка әгъзалары административ комиссиядә, әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, иҗтимагый башлангычларда эшлиләр. Җаваплы сәркатип булмаганда, әлеге бурычлар административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән комиссиянең теләсә кайсы әгъзасына вакытлыча йөкләнә.

2.5. Арча районы башкарма комитеты карары буенча административ комиссиянең башка әгъзалары үз вазыйфаларын даими түләүле нигездә җирле бюджет акчалары исәбеннән башкара алалар.

2.6. Административ комиссия рәисе административ комиссия рәисе урынбасарлары һәм җаваплы сәркатибе арасында вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы Законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели.

2.7. Административ комиссия тарафыннан килүчеләр кабул ителергә мөмкин. Килүчеләрне кабул итү тәртибе административ комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.8 Административ комиссия адресына кергән гражданнар һәм юридик затлар шикаятьләре һәм мөрәҗәгатьләре гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда карала.

2.9 Административ хокук бозулар буенча эшләр административ комиссиядә саклана һәм 2 елдан соң Арча муниципаль районы архивына тапшырыла.

## 3. Административ комиссия утырышын чакыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә административ комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.2. Административ хокук бозулар турындагы эшләр административ комиссия тарафыннан утырышларда карала. Административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турындагы карар административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән саен административ комиссия рәисе тарафыннан, ә ул булмаганда – Рәис тарафыннан билгеләнә торган Рәис урынбасарларының берсе тарафыннан айга кимендә ике тапкыр кабул ителә.

3.3. Административ комиссия утырышлары административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау срокларының үтәлешен тәэмин итә торган ешлык белән уздырыла.

3.4. Административ комиссиянең җаваплы сәркатибе административ комиссия әгъзаларына административ комиссия утырышын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия утырышын уздыруга кимендә 2 көн кала хәбәр итә.

3.5. Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, комиссия Рәисе, Рәис урынбасары һәм әгъзалары бу хакта административ комиссиянең җаваплы сәркатибенә, кагыйдә буларак, административ комиссия утырышы көненә кадәр 1 эш көне кала хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Административ комиссия утырышында административ комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы була.

3.7. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар, билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.8. Административ комиссия утырышы вакытында кино-, видео- һәм фотога төшерү административ комиссия рәисе рөхсәте белән башкарыла.

## 4. Административ җәза салу турындагы карарны үтәү

4.1. Административ комиссия чыгарган карарлар административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә үтәлә.

4.2. Эш буенча эш алып баруда катнашучы затларның, башка физик һәм юридик затларның административ комиссия чыгарган карарларны, билгеләмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәвен тикшереп торуны административ комиссиянең җаваплы секретаре гамәлгә ашыра.

## 5. Административ хокук бозуларны кисәтү

5.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында административ комиссия үз эшчәнлеген эчке эшләр органнары, федераль суд приставлары хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, башка органнар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән координацияли.

5.2. Административ комиссия административ хокук бозулар турында беркетмәләр һәм башка материаллар кергән саен күчмә утырышлар үткәрә, шул исәптән муниципаль район җирлекләрендә дә.

5.3. Административ комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм халык арасында аңлату эшләре уздыру юлы белән профилактик эшне оештыра.